Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советы
КАРАРЫ

25 май 2023 ел № 83

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Олы Кариле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 17 декабрендәге 75 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында»һәм «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм «Конкуренцияне яклау турында» 2022 елның 19 декабрендәге 541-ФЗ номерлы Федераль законның 18-1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Олы Кариле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында»2013 елның 17 декабрендәге 75 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 27 статьясының 5 өлеше 5 пункты түбәндәге эчтәлектәге 5.1 пункты белән тулыландырырга:

«5.1. Әгәр мондый килешү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 40.1 маддәсендә каралган булса, капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше кыяфәтен килештерү»;

1.1.28 статьяның 7 пунктында «башкарма документлар составы һәм аларны алып бару тәртибе,» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Олы Кариле
авыл җирлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Олы Кариле
авыл җирлеге Советы рәисе Ф.Г.Гарифуллин